

Айсылу Мәхмvт кызы Семочкина, Торбеево районара хастаханәсенен баш табибы:
- Мордовия Республикасы Башлыгы Владимир Волков Дәvләт Жыенына еллык Юлламасында, перспективага тобәкнен vсешен билгеләvче топ сәяси документта, зур блок тормыш очен моһим тармак - сәламәтлек саклау олкәсенә багышланган иде. Аерым алганда, тобәк лидеры Мордовиянен инфраструктурасын камилләштерvгә, ресурс белән тәэмин итvгә, технологик жиһазлауга һәм оештыру системасын камилләштерvгә 8 миллиард сум юнәлдерәчәк, дип билгеләп vтте. Акчалар беренче чиратта беренчел медицина һәм санитар ярдәм кvрсәтvгә, балалар медицинасын модернизацияләvгә, йорәк–кан тамырлары авырулары һәм онкология белән корәшкә тотылачак.
Федераль бюджеттан республика авылларында  фельдшер – амбулатория пунктларын тозv һәм реконструкцияләv очен 226 миллион сум акча алачак. Шуны да билгеләп vтәргә кирәк, эле генә Красноармейский поселогында яна модульле ФАП файдалануга тапшырылды. Сәламәтлек саклау тармагы хезмәткәрләре алдында милли проектлар белән тулысынча килешелә торган бик кvп моһим мәсьәләләр куелган. Һәм безнен бурыч - медицина ярдәмен һәркем алырлык итv, аны сыйфатлы яна дәрәжәгә чыгару очен ботен кочне куярга.
Сонгы вакытта безнен районда Торбеево районара хастаханәсен, янәсе, Зубово-Поляна сәламәтлек саклау учреждениесенә кушарга телиләр, дигән имеш-мимешләр йори. Якташларымны тынычландырып шуны әйтәсем килә: безнен дәвалау учреждениебезне бернинди башка торгә кушмаячаклар: имеш-мимешләр ботенләй нигезсез. Шулай ук хезмәткәрләр һәм койка фондында да зур кыскарулар булмаячак. Исегезгә тошерәм, бvген Торбеево МБда тәvлек буе эшли торган стационар очен йоз оч койка эшли, шуларнын егермесе паллиатив. Элеккечә vк кондезге стационар нәтижәле эшләячәк, ерак авылларда яшәvчеләрне дәвалауга махсус «ГАЗель» автомобильләрендә йортәләр. Yзгәрешләр дәвалау процессында турыдан-туры катнашмаган персоналга гына кагыла. Халыкнын кими баруын исәпкә алып, бу чара бик кирәк булды. Һәм ул медицина ярдәмен кvрсәтv сыйфатында берничек тә чагылыш тапмаячак.
Владимир Волков хәбәр иткәнчә, республикада медицина учреждениеләрен кадрлар белән тәэмин итv сәламәтлек саклаунын ин кискен проблемаларынын берсе булып кала. Шуна бәйле рәвештә ин беренче ориентирларнын берсе булып, һонәргә югары медицина технологияләренен клиник нәтижәлелеген, диагностика һәм дәвалаунын яна методларын тәэмин итә алырлык заманча белемнәре булган яшь белгечләрне жәлеп итv

тора. Авыл жирлегендә табиблар һәм фельдшерлар «Земский доктор» максатчан программасын һәм кызыксындыру характерындагы остәмә тvләvләрне жәлеп итәргә тиеш. Һәм без вакантлы вазыйфаларга югары квалификацияле яшь табибларны жәлеп итv очен кулдан килгәннен барысын да эшләячәкбез.
Тагын бер яналык - медицина оешмасынын яна моделен булдыру турында сойлим. Торбеево поселогындагы Поликлиника аны гамәлгә ашыруда 2019 елнын икенче кварталыннан башлап актив катнаша башлады. Биредә яна форматтагы регистратура эшли башлаячак. Анда регистратор һәм килvчеләр арасында киртә булмаячак, алар ачык кинлектә бер-берсе белән аралашачак. Килеп чыккан бәхәсләрен тиз арада хәл итv һәм пациентлар агымын чикләv очен унайлы холлда администратор дежур торачак.
Медицина оешмасы эшен яхшыртуда тагын бер адым - Үзәк (Центр) эше. Регистратурага кергән барлык шалтыратуларны операторлар кабул итәчәк. Яна концепциядә «Глонасс» системасын урнаштыру каралган, ул сакчыл житештерv принцибы буенча медицина учреждениесенен икътисади (экономический) нәтижәлелеген арттыруга юнәлдерелгән.
Сәламәтлек сак-лау системасында модернизациянен нәтижәсе булып пациентнын ихты-яжларына юнәлдерелгән медицина оешмасы тора. Анын яхшы билгеләре булып авыру һәм сәламәт кешеләргә агымны аерунын оптимизацияләнгән логистикасы, электрон документы әйләнешенә тулы кvчv, вакытны экономияләv һәм табибка кабул итv чиратлары булмау, унайлы котv зоналарын булдыру тора. Шунын белән беррәттән, кондәлек практикада сәламәтлек саклаунын беренчел звеносында профилактик чараларнын, диспансерлаштырунын һәм амбулатор – поликлиника шартларында медицина хезмәтләрен кvрсәтv сыйфатыннан халыкнын канәгать булу дәрәжәсенен әһәмияте зур.

**Наилә Насырова**